КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 29 май г.Казань № 652

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджетыннан кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булган индустриаль (сәнәгать) паркларның резидентларына һәм идарәче компанияләренә кулланылган электр энергиясе өчен чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 28 июнь, 505 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджетыннан кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булган индустриаль (сәнәгать) паркларның резидентларына һәм идарәче компанияләренә кулланылган электр энергиясе өчен чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджетыннан кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булган индустриаль (сәнәгать) паркларның резидентларына һәм идарәче компанияләренә кулланылган электр энергиясе өчен чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 28 июнь, 505 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 1 сентябрь, 940 нчы, 2023 ел, 6 март, 212 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы бюджетыннан кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булган индустриаль (сәнәгать) паркларның резидентларына һәм идарәче компанияләренә кулланылган электр

энергиясе өчен чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта:

ундүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2023 елның 1 гыйнварыннан заявка бирү аеның 1 көненә кадәр бирелгән Федераль салым хезмәтенең "Салым түләүченең, җыем түләүченең, иминият кертемнәрен түләүченең яисә салым агентының бердәй салым түләве сыйфатында санап үтелгән акчаларның суммалары һәм аны электрон рәвештә тапшыру форматы турында белешмә формасын раслау хакында" 2022 елның 30 ноябрендәге ЕД-7-8/1129@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча салым түләүченең, җыем түләүченең, иминият кертемнәрен түләүченең яисә салым агентының бердәм салым түләве сыйфатында саналган акчаларның суммалары турында салым органы белешмәсе;»;

уналтынчы абзацта «теркәлгән» сүзен «рәсмиләштерелгән» сүзенә алмаштырырга, «раслаучы» сүзен «раслый торган» сүзләренә алмаштырырга, «аның таныкланган күчермәсе» сүзләрен «аның таныкланган күчермәсе» сүзләренә алмаштырырга;

унҗиденче абзацта «аңлатма язуы» сүзләрен «аңлатма язуы» сүзләренә алмаштырырга, «эчтәлеге» сүзен «булган» сүзенә алмаштырырга, «таныкланган» сүзен «таныкланган» сүзенә алмаштырырга;

3.2 пунктта:

беренче абзацта «белешмә» сүзен «белешмәләр» сүзенә алмаштырырга;

икенче абзацта «өземтә» сүзен «өземтәләр» сүзенә алмаштырырга;

өченче абзацта «өземтә» сүзен «өземтәләр» сүзенә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «килешү» сүзен «килешүләр» сүзенә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин